ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22 05 2020 г. № 323

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:

«2020 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә:

- ата-ана-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәренә (әлеге вазыйфада 1 тулы ставкага эшләүче кече тәрбияче) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана торган карау һәм тәрбия өчен ата-ана түләвенең уртача күләменнән 30% күләмендә.».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 17 июнендәге 982 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы

карарына үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган Тәртипкә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- ата-ана-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәренә (әлеге вазыйфада 1 тулы ставкага эшләүче кече тәрбияче) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана торган карау һәм тәрбия өчен ата-ана түләвенең уртача күләменнән 30% күләмендә.».

- 1.5 пунктының 1 абзацында «компенсация күләме» сүзләреннән соң «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 2 һәм 3 абзацларында күрсәтелгән гражданнарга карата» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле 1.7 пункт өстәргә:

«1.7. Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 4 абзацында күрсәтелгән гражданнарга карата компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$КЗ= СРР*30\%,$$ кайда:

КЗ – гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә компенсация күләме;

СРР-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен алына торган ата-ана түләвенең уртача күләме.

Компенсация Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән айдан билгеләнә.».

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 893 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 4 маендагы 874 номерлы «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы А.Р.Фәретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов